# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы**
**Бикбау авыл җирлеге составына кергән Ахматовка торак пунктында**
**халык җыены нәтиҗәләре турында**

**14.11.2020ел.** **№3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 14 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыенының йомгаклау беркетмәсе түбәндәге мәсьәлә буенча төзелде:

"2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Ахматовка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 1500 сум күләмендә (*1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, БВС һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары,күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнадан тыш*) үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?":

1. “ТР Минзәлә муниципал районы Бикбау авыл җирлеге составына кергән Ахматовка торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында” 2019 елның 17 ноябрендә узган халык җыенында кабул ителгән 3 нче номерлы карар нигезендә 2020 елда Бикбау авыл җирлеге бюджетына гражданнардан кергән үзара салым акчаларының калган өлешен җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?”

*- Куян һәм Ахматовка торак пунктлары арасында вак таш җәю.*

2020 елда җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

*Куян һәм Ахматовка торак пунктлары арасында юлларны ремонтлау өчен торбалар сатып алу һәм сузу* (материал сатып алу, килешү нигезендә түләү)

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Ахматовка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?

*- Куян һәм Ахматовка торак пунктлары арасында вак таш җәю.*

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 15 халык җыенында катнашучы кертелгән, халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 10 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 10 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Ахматовка торак пунктында халык җыены узуын таныrга, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныrга.

Түбәндәге мәсьәләләр буенча карарларны танырга:

1. “ТР Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлеге составына кергән Ахматовка торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында” 2019 елның 17 ноябрендә узган халык җыенында кабул ителгән 3 нче номерлы карар нигезендә 2020 елда Бикбау авыл җирлеге бюджетына гражданнардан кергән үзара салым акчаларының калган өлешен җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?”

*Куян һәм Ахматовка торак пунктлары арасында вак таш җәю.*

2020 елда җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

*Куян һәм Ахматовка торак пунктлары арасында юлларны ремонтлау өчен торбалар сатып алу һәм сузу* (материал сатып алу, килешү нигезендә түләү).

2. “2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Ахматовка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?”

- *Куян һәм Ахматовка торак пунктлары арасында вак таш җәю.*

2. Бикбау авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (https://menzelinsk.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Бикбау авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче ______________Л.Н.Мәрдәмшина

**Бикбау авыл җирлеге башлыгы:** **Л.Н. Мәрдәмшина**